Татарстан Республикасы

Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

№ 115

23.04.2018 ел

**«Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында»**

Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне расларга.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы «Түбән Биш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең, муниципаль вазыйфаларга карамый торган вазыйфа башкаручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 20 февралендәге 54 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләрен һәм локаль актларны әлеге нигезләмәгә туры китерергә.

5. Карарны Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге**
**башлыгы** **Д.В.Насертдинов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Түбән Биш авыл җирлеге
Советының 2018 елның
23 апрелендәге
115 номерлы карары белән
расланган.

**Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. Нигезләмә Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, белгечләргә хезмәт өчен түләү мәсьәләләре буенча норматив - хокукый актларны системалаштыра, хезмәткә түләүнең иң чик күләмнәрен билгели.

## 2. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, җирле үзидарә органнары белгечләренең хезмәте өчен түләү

2.1. Муниципаль хезмәткәр хезмәте өчен түләү муниципаль хезмәткәрнең үзе биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы (алга таба – вазыйфаи оклад) нигезендә муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладыннан, шулай ук әлеге нигезләмә белән билгеләнә торган айлык һәм башка өстәмә түләүләрдән (алга таба – өстәмә түләүләр) торган акчалата керем рәвешендә башкарыла.

Өстәмә түләүләргә түбәндәгеләр керә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү;

2) муниципаль хезмәтнең аерым шартлары (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттәге югары казанышлар, махсус эш режимы) өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү;

3) түләү тәртибе муниципаль органның бурычларын һәм функцияләрен тәэмин итүне, вазифаи инструкцияне үтәүне исәпкә алып, яллаучы вәкиле (эш бирүче) тарафыннан билгеләнә торган аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр;

4) айлык акчалата бүләкләү;

5) класс чины өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү;

6) чираттагы еллык түләүле ял алганда бер тапкыр бирелә торган түләү;

7) матди ярдәм.

2.2. Муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәтнең биләгән муниципаль вазыйфасына бәйле рәвештә вазыйфаи окладлар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең 11 163 сум вазыйфаи окладына кабатлы күләмдә билгеләнә.

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын исәплләгәндә кулланыла торган коэффициентлар 1 нче кушымтада китерелә.

Вазыйфаи окладларның күләме арту ягына бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш.

2.3. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына карата түбәндәге процентларда билгеләнә:

| муниципаль хезмәт стажы | өстәмәләр күләме процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15 |
| 15 елдан артык | 20 |

2.4. Муниципаль хезмәткәргә классы чин өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Классы чин | Классы чин өчен өстәмә түләү күләме (вазыйфаи окладка карата процентларда) |
|---|---|
| I классы хакыйкый муниципаль киңәшче<br>I классы муниципаль киңәшче<br>I классы муниципаль хезмәт киңәшчесе<br>I классы муниципаль хезмәт референты<br>I классы муниципаль хезмәт секретаре | 7 |
| II классы хакыйкый муниципаль киңәшче | 5 |

| | |
|---|---|
| II классلы муниципаль киңәшче<br>II класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе<br>II класслы муниципаль хезмәт референты<br>II класслы муниципаль хезмәт секретаре | |
| III класслы хакыйкый муниципаль киңәшче<br>III класслы муниципаль киңәшче<br>III класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе<br>III класслы муниципаль хезмәт референты<br>III класслы муниципаль хезмәт секретаре | 3 |

2.5. Муниципаль хезмәтнең аерым шартлары (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә югары казанышлар, махсус эш режимы) өчен муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына айлык өстәмә түләү җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

югары муниципаль вазыйфалар өчен - вазыйфаи окладның 9 проценты;

төп муниципаль вазыйфалар өчен - вазыйфаи окладның 7 проценты;

әйдәп баручы муниципаль вазыйфалар өчен - вазыйфаи окладның 5 проценты;

өлкән муниципаль вазыйфалар өчен - вазыйфаи окладның 3 проценты;

кече муниципаль вазыйфалар өчен - вазыйфаи окладның 1 проценты күләмендә.

Эш стажы һәм класс чины өчен өстәмә түләүләре булмаган муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә җитәкче күрсәтмәсе буенча өстәмә түләүләр билгеләнергә мөмкин.

2.6. Муниципаль хезмәткәргә вазыйфаи окладның бер проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү түләнә.

2.7. Муниципаль хезмәткәрләргә вазыйфаи окладның 1 проценты күләмендә ай саен премия түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль орган бурычларын һәм функцияләрен үтәүне тәэмин итүне, вазыйфаи инструкцияне үтәүне исәпкә алып, аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне башкарган өчен премияләр түләнә.

Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне (алга таба - премияләр) үтәгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә премияләр бер мәртәбә, ай саен, квартал саен һәм әлеге Нигезләмә нигезендә кабул ителгән җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе карары буенча эш нәтиҗәләре буенча түләнә ала.

Премияләр түләү шулай ук башкарылырга мөмкин:

- билгеле бер чорда эш нәтиҗәләре буенча;

-дәүләт бәйрәмнәренә, истәлекле, юбилей, тантаналы даталарга бәйле рәвештә.

Премияләр муниципаль хезмәткәрләргә шушы максатларга җирле үзидарә органының хезмәт өчен түләү фондында каралган акчалар чикләрендә яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан яисә муниципаль берәмлек бюджетында, җирле үзидарә органында өстәмә чыганаклар

булганда (хезмәткә түләү фондыннан тыш) түләнә һәм түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

- җирле үзидарәнең тиешле органына һәм муниципаль органга йөкләнгән бурычларны, вазыйфаларны үтәүне тәэмин итү һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча хезмәткәрнең шәхси өлеш кертүе;

- хезмәткәрләр үтәгән биремнең катлаулылыгы, мөһимлеге һәм сыйфаты, ирешелгән нәтиҗәләр;

- хезмәткәрнең вазыйфаи инструкцияне үтәү нәтиҗәләре;

- хезмәт дисциплинасын үтәү.

Премияләр күләме абсолют күләмдә (сумнарда) һәм шулай ук муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасы буенча акчалата чагылыштa яисә вазыйфаи окладларга кабатлы итеп билгеләнә ала.

Бер ел эчендә премияләрнең гомуми күләме муниципаль хезмәткәрнең айлык дүрт хезмәт хакыннан артып китә алмый.

2.8. Еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләү муниципаль хезмәткәрләргә биләгән вазыйфасы буенча муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладының 120 проценты күләмендә бирелә.

Чираттагы түләүле ял өлешләп бирелгән очракта, муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган түләү, аның гаризасы буенча, хезмәткәргә ялның теләсә кайсы өлешен биргәндә, бер тапкыр түләнә. Муниципаль хезмәткәр гаризасы буенча бер тапкыр бирелә торган түләү шулай ук календарь ел дәвамында түләнергә мөмкин.

Әгәр муниципаль хезмәткәргә календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган түләү билгеләнгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм декабрь аенда түләнә, муниципаль хезмәткәр эштән киткән очракта – хезмәт килешүен туктаткан соңгы эш көненнән соңармый башкарыла.

Чираттагы түләүле ялга чыкканда муниципаль хезмәткәргә беренче эш елында бер тапкыр түләнә торган түләү календарь елда эш башкарган вакытка пропорциональ итеп исәпләп чыгарыла. Эшләнгән вакыт итеп эшкә кергән көннән агымдагы елның 31 декабренә кадәр ара исәпләнә.

2.9. Хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә муниципаль хезмәткәрләргә юбилей даталары, никахлашу, бала туу, ире (хатыны) яисә якын туганы вафат булу һәм башка вакыйгалар белән бәйле рәвештә елга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтелергә мөмкин.

2.10. Бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәләрне, катлаулылык һәм киеренкелек, акчалата бүләкләүне һәм классны чинны исәпкә алып, биләгән вазыйфасы буенча көнлек хезмәт хакының икеләтелгән күләмендә түләнә.

2.11. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның хезмәтенә түләү айлык акчалата түләү рәвешендә башкарыла. Акчалата түләү күләме 2 нче кушымтада бирелгән. Айлык акчалата түләүдән тыш, җирлек башлыгына өстәмә рәвештә түбәндәгеләр билгеләнә:

- айлык акчалата бүләкләүнең 91,66 проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

- нигезләмәнең 2.3 пунктында билгеләнгән күләмдә тиешле еллар эшләгән өчен акчалата бүләкләүгә айлык өстәмә түләү;

2.12. Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларга премияләр бирелә ала:

- аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен бер тапкыр, ай саен, квартал саен һәм бер еллык эш нәтиҗәләре буенча түләнә ала торган түләүләр;

- эш нәтиҗәләре буенча;

- дәүләт бәйрәмнәре, истәлекле, юбилей, тантаналы даталар уңаеннан.

Премияләр күләме абсолют күләмдә (рубльләрдә) һәм шулай ук акчалата хезмәт хакы яки акчалата бүләкләүдә билгеләнергә мөмкин.

2.13. Җирлек башлыгына чираттагы түләүле ялга чыкканда елга бер мәртәбә бер акчалата бүләк күләмендә түләү бирелә.

Чираттагы түләүле ял өлешләп бирелгән очракта, җирлек башлыгына бер тапкыр бирелә торган түләү, аның гаризасы буенча, ялның теләсә кайсы өлешен биргәндә, бер тапкыр түләнә. Җирлек башлыгы гаризасы буенча бер тапкыр бирелә торган түләү шулай ук календарь ел дәвамында түләнергә мөмкин.

Әгәр җирлек башлыгына календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган түләү билгеләнгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм декабрь аенда түләнә, эштән киткән очракта – хезмәт килешүен туктаткан соңгы эш көненнән соңармый башкарыла.

Чираттагы түләүле ялга чыкканда җирлек башлыгына беренче эш елында бер тапкыр түләнә торган түләү календарь елда эш башкарган вакытка пропорциональ итеп исәпләп чыгарыла. Эшләнгән вакыт итеп эшкә кергән көннән агымдагы елның 31 декабренә кадәр ара исәпләнә.

2.14. Җирлекнең җирле үзидарә органнары белгечләренең хезмәте өчен түләү вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт хакына ай саен өстәмә түләүдән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүдән, ай саен акчалата бүләкләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премиядән, чираттагы түләүле ялга чыкканда бер мәртәбә бирелә торган түләүдән, матди ярдәмнән, шулай ук законнар нигезендә каралган башка түләүләрдән гыйбарәт.

Белгечләрнең вазыйфаи окладлары күләме вазыйфаи окладлар күләменә, ул 11163 сум тәшкил итә, кабатлы итеп исәпләнә.

Белгечләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен санаганда кулланыла торган кабатлылык коэффициентлары 3 нче кушымтада билгеләнгән.

2.15. Белгечләргә билгеләргә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен түбәндәге күләмнәрдә өстәмә:

| хезмәт стажы | өстәмәләр күләме |
|---|---|

| | процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә айлык өстәмә түләү;

3) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

5) чираттагы түләүле ялга чыкканда вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә елга бер тапкыр бирелә торган түләү.

Чираттагы түләүле ялга чыкканда белгечкә беренче эш елында бер тапкыр түләнә торган түләү календарь елда эш башкарган вакытка пропорциональ итеп исәпләп чыгарыла. Эшләнгән вакыт итеп эшкә кергән көннән агымдагы елның 31 декабренә кадәр ара исәпләнә. Чираттагы түләүле ял өлешләп бирелгән очракта, белгечкә бер тапкыр бирелә торган түләү, аның гаризасы буенча, хезмәткәргә ялның теләсә кайсы өлешен биргәндә, бер тапкыр түләнә. Белгеч гаризасы буенча бер тапкыр бирелә торган түләү шулай ук календарь ел дәвамында түләнергә мөмкин. Әгәр белгечкә календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган түләү билгеләнгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм декабрь аенда түләнә, белгеч эштән киткән очракта – хезмәт килешүен туктаткан соңгы эш көненнән соңармый башкарыла.

6) хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә матди ярдәм.

2.16. Белгечләргә үзләренең төп эше белән беррәттән, вакытлыча булмаган хезмәткәрнең вазыйфаларын алып барган, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткән өчен, хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә, төп эш буенча вазыйфаи окладның 50 проценты күләмендә билгеләнгән вазыйфаи окладны үтәгән өчен өстәмә түләү билгеләргә.

2.17. Бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен белгечләргә хезмәт хакы, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәләрне, катлаулылык һәм киеренкелек, акчалата бүләкләүне исәпкә алып, биләгән вазыйфасы буенча икеләтә хезмәт хакы күләмендә башкарыла.

2.18. Хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә белгечләргә һәм эшчеләргә юбилей даталары, никахлашу, бала туу, ире (хатыны) яки якын туганнары үлү һәм башка вакыйгалар уңаеннан бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтелә ала.

## 3. Муниципаль берәмлекләр хезмәткәрләренә башка өстәмә түләүләр

3.1. Эш бирүче (яллаучы вәкиле) хезмәткәрләргә гамәлдәге законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә башка өстәмә түләүләр түләргә хокуклы.

Зәй муниципаль районы
Түбән Биш авыл җирлеге
Советының 2018 елның
23 апрелендәге 115 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Түбән Биш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын исәпләгәндә кулланыла торган коэффициентлар таблицасы

| Вазыйфаларның аталышы | Коэффициентлар |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 1,37 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (секретарь) | 1,33 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,11 |
| 1 категорияле белгеч,<br>2 категорияле белгеч,<br>белгеч | 1,00 |

Зәй муниципаль районы
Түбән Биш авыл җирлеге
Советының 2018 елның
23 апрелендәге 115 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Түбән Биш авыл җирлеге башлыгына акчалата бүләк күләме

| Вазыйфаның аталышы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 11 701 |

Приложение № 3
к решению Совета
Нижнебишевского сельского
поселения Заинского
муниципального района
от 23.04.2018г. № 115

Коэффициенты кратности, применяемые при исчислении размеров должностных окладов специалистов органов местного самоуправления

| Наименование должностей | коэффициент |
|---|---|
| Главный специалист | 1,10 |
| Ведущий специалист | 1,05 |
| Специалист I категории | 1,00 |